# Әти-әниләр белән бергә

Балалар бакчасы ел буе балаларга эзлекле белем бирү, физик яктан чыныккан, сәламәт, табигатьне саклый белүче балалар тәрбияләү өстендә эшләде. Белем һәм тәрбия бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениеләренең эшен нәтиҗәле итү өчен яңа идеяләр, белем – тәрбия бирүдә инновацион технологияләр кулану кирәк.

Бакчада балаларның физик, интелллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә нык игътибар ителде.

Ел башында балалар бакчасының укыту – тәрбия планнары, шөгыльләр челтәре төзелде, бакча мөдире тарафыннан расланды һәм гамәлгә кертелде. Ел дәвамында төркемнәрдә эшләүче тәрбиячеләр даими рәвештә режим моментларын үтәп, яңа алымнар кулланып эшләделәр.

Уку елы бер -бер артлы уздырылган чаралар белән тыгыз бәйләнеп барылды. Район, авыл күләмендә үткәрелгән чараларда актив катнашып бардык. Бакчада һәрбер бәйрәм оешкан төстә узды. Ел әйләнәсендә балалар һәм әти – әниләр, әби - бабайлар белән күп кенә чаралар уздырылды.

Өлкәннәр көне уңаеннан оештырылган кичә балаларга гына түгел бакча тәрбиячеләренә дә бик ошады.

Октябрь аенда саф һавада уздырылган -«Без житезләр.»- дип исемләнгән спорт бәйрәмендә балалар, әти -әниләр генә түгел, дәү әниләр һәм дәү әтиләрдә бик теләп катнаштылар. Шулай ук бакчада спортның кышкы төрләренә зур игътибар бирелә. Һәр елны участокта тау ясала, чаңга трассасы салына һәм тәрбиячеләр белән балалар чаңгы шуалар. Балаларның сәламәтлеген саклауга аеруча зур игътибар бирелә. Бакчада әниләр көненә карата уздырылган «Әниемнең йомшак куллары»; яңа елга «Кыш бабайда кунакта»; ватанны саклаучылар көненә «Әтием горурлыгым»; яз бәйрәменә «Пар канатларым» - дип исемләнгән бәйрәм иртәләре балаларның һәм тәрбиячеләрнең зур әзерлеге белән билгеләп үтелде.

Бакчада уздырылган бәйрәмнәр белән беррәттән тәрбиячеләребез район конкурсларында да теләп катнаштылар.

Яңа елга балалар бакчасы территориясен кардан ясалган сыннар белән бизәп авыл советы буенча оештырылган конкурста III урынны алуга ирештек. Март аенда авыл мәдәният йортында бакчада тәрбияләнүче балалар һәм тәрбиячеләр көче белән әзерләнгән “Без – бит авыл баласы” дип исемләнгән зур сәнгать бәйрәме оештырылды.

. Беренче өлештә - КВН, икенче өлештә концерт булды. Концерт – оешкан рәвештә, бик матур булды.

Май аенда балалар һәм бакча хезмәткәрләре белән берлектә “кече Сабантуй” бәйрәме уздырылды.

Жирле үзидарә тарафыннан оештырылган авыл бәйрәмнәрендә бакча хезмәткәрләре бик теләп катнашалар һәм призлы урыннар яулыйлар.

Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары пожарга каршы, Г.Тукай әсәрләре буенча оештырылган рәсем конкурсларында катнашты.

Узган уку елында әти -әниләр белән эшләүгә зур игътибар бирелде. Аеруча әтиләрнең бакчага ярдәме бик зур. Бу уку елында һәр төркемнең әтиләре төркемнәрнең уен почмакларына мебельләр ясап бирделәр (кухня, парикмахер, кибет почмаклары).Шулай ук участокны бизәүдә әтиләрнең көче күп керде. Бу уку елында да әти - әниләр белән эшләүгә зур бурычлар куелды. Иң мөхиме әти - әниләр арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

Бакчаның материаль – техник базасын ныгытуга да бик зур игътибар бирелә. Бүлмәләрдә косметик ремонтлар уздырылды, керү юллары пожар куркынычсызлыгы кагыйдәләренә туры китерелеп эшләнелеп барыла. Бакчабызны бик күп төрле чәчәкләр бизи, хезмәткәрләр көче белән бәрәңге, суган, чөгендер, кишер, кабак үстерелде. Үзебездә үскән чиядән, алмадан кайнатмалар ясалды.

Яңа ел бәйрәменнән күренешләр









Әтиләр бәйрәменнән күренешләр





















2016 ел, февраль